МИНИСТЕРСТВО
ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ
И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН
ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ
ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

11.07.2016 № 398

г.Казань

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2016 елның 10 августында теркәлде, № 3467

Пенсия белән Россия Федерациясе
Пенсия фонды тарафыннан тәэмин ителүче
хәрби хезмәт бурычларын (хезмәт итү бурычларын)
үтәгәндә һәлак булган (үлгән, үлгән дип игълан ителгән,
хәбәрсез килеш монда юк дип танылган)
хәрби хезмәткәрләрнең һәм кайбер федераль
башкарма хакимият органнары хезмәткәрләренең
аерым категорияләре балаларына
һәм хәрби хезмәттән (органнарда һәм учреждениеләрдә
хезмәт итүдән) азат ителгәннән соң
хәрби җәрәхәт аркасында үлгән затларның
балаларына ай саен бирелә торган
пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең
Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны
эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының
20.06.2012 ел, № 444 боерыгы белән расланган
административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында

Пенсия белән Россия Федерациясе Пенсия фонды тарафыннан тәэмин ителүче, хәрби хезмәт бурычларын (хезмәт итү бурычларын) үтәгәндә һәлак булган (үлгән, үлгән дип игълан ителгән, хәбәрсез килеш монда юк дип танылган) хәрби хезмәткәрләрнең һәм кайбер федераль башкарма хакимият органнары хезмәткәрләренең аерым категорияләре балаларына һәм хәрби хезмәттән (органнарда һәм учреждениеләрдә хезмәт итүдән) азат ителгәннән соң хәрби җәрәхәт аркасында үлгән затларның балаларына ай саен түләнә торган пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү эшен камилләштерү максатларында **боерык бирәм:**

1. Кушымта итеп бирелүче яңа редакциядә бәян итеп, Пенсия белән Россия Федерациясе Пенсия фонды тарафыннан тәэмин ителүче, хәрби хезмәт

1. Кушымта итеп бирелүче яңа редакциядә бәян итеп, Пенсия белән Россия Федерациясе Пенсия фонды тарафыннан тәэмин ителүче, хәрби хезмәт бурычларын (хезмәт итү бурычларын) үтәгәндә һәлак булган (үлгән, үлгән дип игълан ителгән, хәбәрсез килеш монда юк дип танылган) хәрби хезмәткәрләрнең һәм кайбер федераль башкарма хакимият органнары хезмәткәрләренең аерым категорияләре балаларына һәм хәрби хезмәттән (органнарда һәм учреждениеләрдә хезмәт итүдән) азат ителгәннән соң хәрби җәрәхәт аркасында үлгән затларның балаларына ай саен түләнә торган пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының “Пенсия белән Россия Федерациясе Пенсия фонды тарафыннан тәэмин ителүче, хәрби хезмәт бурычларын (хезмәт итү бурычларын) үтәгәндә һәлак булган (үлгән, үлгән дип игълан ителгән, хәбәрсез килеш монда юк дип танылган) хәрби хезмәткәрләрнең һәм кайбер федераль башкарма хакимият органнары хезмәткәрләренең аерым категорияләре балаларына һәм хәрби хезмәттән (органнарда һәм учреждениеләрдә хезмәт итүдән) азат ителгәннән соң хәрби җәрәхәт аркасында үлгән затларның балаларына ай саен түләнә торган пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында” 20.06.2012 ел, № 444 боерыгы белән расланган административ регламентына (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 04.09.2014 ел, № 482, 07.06.2016 ел, № 317 боерыклары керткән үзгәрешләр белән) үзгәрешләр кертергә.

**Министр в.б.** **М.Р. Гафаров**

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 20.06.2012 ел, № 444 боерыгы белән расланды
(Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 11.07.2016 ел, № 398 боерыгы редакциясендә).

**Пенсия белән Россия Федерациясе Пенсия фонды тарафыннан тәэмин ителүче, хәрби хезмәт бурычларын (хезмәт итү бурычларын) үтәгәндә һәлак булган (үлгән, үлгән дип игълан ителгән, хәбәрсез килеш монда юк дип танылган) хәрби хезмәткәрләрнең һәм кайбер федераль башкарма хакимият органнары хезмәткәрләренең аерым категорияләре балаларына һәм хәрби хезмәттән (органнарда һәм учреждениеләрдә хезмәт итүдән) азат ителгәннән соң хәрби җәрәхәт аркасында үлгән затларның балаларына ай саен түләнә торган пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Пенсия белән Россия Федерациясе Пенсия фонды тарафыннан тәэмин ителүче, хәрби хезмәт бурычларын (хезмәт итү бурычларын) үтәгәндә һәлак булган (үлгән, үлгән дип игълан ителгән, хәбәрсез килеш монда юк дип танылган) хәрби хезмәткәрләрнең һәм кайбер федераль башкарма хакимият органнары хезмәткәрләренең аерым категорияләре балаларына һәм хәрби хезмәттән (органнарда һәм учреждениеләрдә хезмәт итүдән) азат ителгәннән соң хәрби җәрәхәт аркасында үлгән затларның балаларына ай саен түләнә торган пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең бу административ регламенты (алга таба – Регламент) пенсия белән Россия Федерациясе Пенсия фонды тарафыннан тәэмин ителүче, хәрби хезмәт бурычларын (хезмәт итү бурычларын) үтәгәндә һәлак булган (үлгән, үлгән дип игълан ителгән, хәбәрсез килеш монда юк дип танылган) хәрби хезмәткәрләрнең һәм кайбер федераль башкарма хакимият органнары хезмәткәрләренең аерым категорияләре балаларына һәм хәрби хезмәттән (органнарда һәм учреждениеләрдә хезмәт итүдән) азат ителгәннән соң хәрби җәрәхәт аркасында үлгән затларның балаларына ай саен түләнә торган пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү (алга таба – дәүләт хезмәте күрсәтү) стандартын һәм тәртибен билгели.

1.2. Дәүләт хезмәте алучылар:

1) түбәндәгеләрнең законлы вәкиле (ата-анасы, уллыкка алучысы, опекуны яки химаячесе):

бала 18 яшькә җиткәнгә кадәр, чакырылыш буенча хәрби хезмәт бурычларын үтәгәндә һәлак булган (үлгән, үлгән дип игълан ителгән, хәбәрсез килеш монда юк дип танылган) хәрби хезмәткәрләрнең, һәм чакырылыш буенча

хәрби хезмәттән азат ителгәннән соң хәрби җәрәхәт аркасында үлгән затларның балаларының;

хәрби хезмәт бурычларын (хезмәт итү бурычларын) үтәгәндә һәлак булган (үлгән, үлгән дип игълан ителгән, хәбәрсез килеш монда юк дип танылган): хәрби хезмәтне контракт буенча узган хәрби хезмәткәрләр, Россия Федерациясе эчке эшләр органнары, Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигать бәла-казаларының нәтиҗәләрен бетерү министрлыгының Янгынга каршы дәүләт хезмәте органнары, җинаять-башкару системасы учреждениеләре һәм органнары, наркотик матдәләр һәм психотроп матдәләр әйләнешен контрольдә тотучы органнар хезмәткәрләре, Россия Федерациясе салым полициясе федераль органнарында хезмәт иткән затлар балаларының, һәм хәрби хезмәттән (органнарда һәм учреждениеләрдә хезмәт итүдән) азат ителгәннән соң хәрби җәрәхәт аркасында үлгән затлар балаларының (туендыручысын югалту очрагы буенча пенсия Россия Федерациясе Пенсия фондыннан түләнә торган);

2) бу пунктның өченче һәм дүртенче абзацларында күрсәтелгән балалар исәбендәге зат:

мәгариф учреждениесендә көндезге көндәлек уку формасында белем алучы – укуын тәмамлаганга кадәр, ләкин 23 яшькә җиткәннән дә артык түгел;

18 яшькә җиткәнгә кадәр инвалидка әверелгән – яшенә бәйсез.

1.3. Дәүләт хезмәте күрсәтүгә гариза бирүчеләр (алга таба – гариза бирүче) булып, бу Регламентның 1.2 пунктында күрсәтелгән дәүләт хезмәте алучылар яки аларның законлы вәкилләре (закон белән күздә тотылган очракларда) яисә билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән ышанычнамә нигезендә эш итүгә дәүләт хезмәте алучылар тарафыннан вәкаләт бирелгән затлар тора.

1.4. Дәүләт хезмәте Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Татарстан Республикасы муниципаль районындагы яки шәһәр округындагы Социаль яклау идарәсе (бүлеге) (алга таба – Идарә (бүлек)) йөзендә Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан, дәүләт хезмәте алучының яшәү урынында күрсәтелә.

1.4.1. Идарәнең (бүлекнең) урнашу урыны, белешмәләр алу өчен телефоннары, электрон почта адреслары бу Регламентка белешмә-кушымтада китерелгән.

Идарәнең (бүлекнең) эш графигы: "Идарәнең (бүлекнең) эчке тәртип кагыйдәләре белән билгеләнүче эш сәгатьләрендә шимбә һәм якшәмбедән тыш көн саен.

1.4.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында мәгълүмат алынырга мөмкин:

1) Идарәләрдә (бүлекләрдә) урнашкан, дәүләт хезмәте күрсәтү турында визуаль һәм текстлы мәгълүматтан торган дәүләт хезмәте турында мәгълүмат стендлары ярдәмендә. Мәгълүмат стендларына урнаштырыла торган мәгълүмат дәүләт хезмәте күрсәтү турында бу Регламентның 1.4.1, 2.1, 2.3, 2.4, 2.5, 2.8, 2.10, 2.11, 5.1 пунктларында (пунктчаларында) булган белешмәләрне үз эченә ала.

2) "Интернет" челтәре ярдәмендә:

Министрлыкның рәсми сайтында: http://www.mtsz.tatarstan.ru;

Татарстан Республикасы Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталыннан (http://uslugi.tatar.ru);

3) Үзәк бүлегенә, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына (алга таба – Министрлык) телдән мөрәҗәгать иткәндә (шәхсән яки телефоннан);

4) Үзәк бүлегенә, Министрлыкка язмача (шул исәптән электрон документ рәвешендә) мөрәҗәгать иткәндә. Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең (функцияләрнең) бердәм порталыннан (http://www.gosuslugi.ru);

3) Идарәгә (бүлеккә), Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына телдән мөрәҗәгать итеп (шәхсән яки телефоннан);

4) Идарәгә (бүлеккә), Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына язмача (шул исәптән электрон документ рәвешендә) мөрәҗәгать итеп.

1.4.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү мәсьәләләре турында мәгълүмат Идарә (бүлек) биналарындагы мәгълүмат стендларына урнаштырыла.

1.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәгеләр нигезендә хәл ителә:

“Персональ мәгълүматлар турында” 27 июль, 2006 ел, № 152-ФЗ Федераль закон (алга таба – № 152-ФЗ Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2006, № 31 (1 өлеш), 3451 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында” 27 июль, 2010 ел, № 210-ФЗ Федераль закон (алга таба – № 210-ФЗ Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2010, № 31, 4179 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Электрон имза турында” 6 апрель, 2011 ел, № 63-ФЗ Федераль закон (алга таба – № 63-ФЗ Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2011, № 15, 2036 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Хәрби хезмәт бурычларын (хезмәт итү бурычларын) үтәгәндә һәлак булган (үлгән, үлгән дип игълан ителгән, хәбәрсез килеш монда юк дип танылган) хәрби хезмәткәрләрнең һәм кайбер федераль башкарма хакимият органнары хезмәткәрләренең балаларына һәм хәрби хезмәттән (органнарда һәм учреждениеләрдә хезмәт итүдән) азат ителгәннән соң хәрби җәрәхәт аркасында үлгән затларның балаларына пособие турында” 4 июнь, 2011 ел, № 128-ФЗ Федераль закон (алга таба – № 128-ФЗ Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2011, № 23, 3268 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Дәүләт идарәсе системасын камилләштерүнең төп юнәлешләре турында” 07.05.2012 ел, № 601 Россия Федерациясе Президенты Указы (алга таба – РФ Президентының № 601 Указы) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2012, № 19, 2338 ст.);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең “Хәрби хезмәт бурычларын (хезмәт итү бурычларын) үтәгәндә һәлак булган (үлгән, үлгән дип игълан ителгән, хәбәрсез килеш монда юк дип танылган) хәрби хезмәткәрләрнең һәм кайбер федераль башкарма хакимият органнары хезмәткәрләренең балаларына һәм хәрби

хезмәттән (органнарда һәм учреждениеләрдә хезмәт итүдән) азат ителгәннән соң хәрби җәрәхәт аркасында үлгән затларның балаларына ай саен түләнә торган пособие турында" 2010 елның 30 июнендәге № 481 карары (алга таба – РФ Хөкүмәтенең № 481 карары) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2010, № 28, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Пенсия белән Россия Федерациясе Пенсия фонды тарафыннан тәэмин ителүче, хәрби хезмәт бурычларын (хезмәт итү бурычларын) үтәгәндә һәлак булган (үлгән, үлгән дип игълан ителгән, хәбәрсез килеш монда юк дип танылган) хәрби хезмәткәрләрнең һәм кайбер федераль башкарма хакимият органнары хезмәткәрләренең аерым категорияләре балаларына һәм хәрби хезмәттән (органнарда һәм учреждениеләрдә хезмәт итүдән) азат ителгәннән соң хәрби җәрәхәт аркасында үлгән затларның балаларына ай саен түләнә торган пособие түләүнең Россия Федерациясе Хөкүмәтенең "Хәрби хезмәт бурычларын (хезмәт итү бурычларын) үтәгәндә һәлак булган (үлгән, үлгән дип игълан ителгән, хәбәрсез килеш монда юк дип танылган) хәрби хезмәткәрләрнең һәм кайбер федераль башкарма хакимият органнары хезмәткәрләренең балаларына һәм хәрби хезмәттән (органнарда һәм учреждениеләрдә хезмәт итүдән) азат ителгәннән соң хәрби җәрәхәт аркасында үлгән затларның балаларына ай саен түләнә торган пособие турында" 2010 елның 30 июнендәге № 481 карары белән расланган кагыйдәләре (алга таба – № 481 карар белән расланган Кагыйдәләр) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2010, № 28, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы мәсьәләләре" 15.08.2007 ел, № 388 карары ("Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнарының норматив актлары җыентыгы" журналы, 2007, № 33, 1178 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

"Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында" 02.11.2010 ел, № 880 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе (алга таба – ТР МК № 880 карары белән расланган Тәртип) ("Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнарының норматив актлары җыентыгы" журналы, 2010, № 46, 2144 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып).

1.6. Бу Регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:

дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урыны – муниципаль районнарның авыл җирлекләрендә документларны кабул итү һәм бирү, гариза бирүчеләргә консультацияләр үткәрү "тәрәзә"се;

техник хата – дәүләт хезмәте күрсәтүче орган тарафыннан җибәрелгән һәм документка (дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсенә) кертелгән мәгълүматларның мәгълүматлар керткәндә нигез булып торган документлардагы мәгълүматларга туры килмәвенә китергән хата (ялгыш язу, басмада ялгышлык, грамматик яки арифметик хата).

Бу Регламентта дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза (алга таба – гариза) төшенчәсе № 210-ФЗ Федераль законның 2 ст. 1 п. белән күздә тотылган дәүләт хезмәтен күрсәтү турында рәсми мөрәҗәгатьне аңлата. Гаризаның киңәш ителә торган формасы бу Регламентка 1 нче кушымтада китерелгән.

## 2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

| Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартына таләп атамасы | Стандарт таләбе эчтәлеге | Дәүләт хезмәтен яки таләпне билгеләүче норматив акт |
|---|---|---|
| 2.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү атамасы | Пенсия белән Россия Федерациясе Пенсия фонды тарафыннан тәэмин ителүче, хәрби хезмәт бурычларын (хезмәт итү бурычларын) үтәгәндә һәлак булган (үлгән, үлгән дип игълан ителгән, хәбәрсез килеш монда юк дип танылган) хәрби хезмәткәрләрнең һәм кайбер федераль башкарма хакимият органнары хезмәткәрләренең аерым категорияләре балаларына һәм хәрби хезмәттән (органнарда һәм учреждениеләрдә хезмәт итүдән) азат ителгәннән соң хәрби җәрәхәт аркасында үлгән затларның балаларына ай саен түләнә торган пособие (алга таба – ай саен түләнә торган пособие) билгеләү | № 128-ФЗ федераль законның 1 ст.;<br>РФ Хөкүмәтенең № 481 карары |
| 2.2. Дәүләт хезмәтен турыдан-туры күрсәтүче орган (учреждение) атамасы | Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Татарстан Республикасы муниципаль районындагы яки шәһәр округындагы Социаль яклау идарәсе (бүлеге) йөзендә Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы | РФ Хөкүмәтенең № 481 карары белән расланган Кагыйдәләрнең 3 п. |
| 2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен тасвирлау | Ай саен түләнә торган пособие билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) карар | РФ Хөкүмәтенең № 481 карары белән расланган Кагыйдәләрнең 5 п. |
| 2.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү срогы, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы | Ай саен түләнә торган пособие билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) карар гариза һәм бу Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар кергән моменттан алып ун | РФ Хөкүмәтенең № 481 карары белән |

| | | |
|---|---|---|
| оешмаларга мөрәҗәгать итү зарурлыгын исәпкә алып; туктатып тору мөмкинлеге Россия Федерациясе законнары белән күздә тотылган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору срогы | эш көне эчендә кабул ителә.<br>Тапшырылган документларны өстәмә тикшерү һәм ай саен түләнә торган пособиене алу өчен нигезләрне дәлилләү зарурлыгы булганда, карар кабул итү срогы озайтылырга мөмкин, бу хакта, сәбәпләрен һәм карар кабул итүнең фаразланучы срогын күрсәтеп, гариза бирүчегә хәбәр ителә. Бу очракта пособие билгеләү турында карар өстәмә тикшерү тәмамланган көннән алып ун эш көне эчендә кабул ителә. | расланган Кагыйдәләрнең 7 п. |
| 2.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булып торган хезмәтләрне күрсәтү өчен, закон яки башка норматив-хокукый актлар нигезендә кирәкле, гариза бирүче тапшырырга тиешле документларның тулы исемлеге, гариза бирүче тарафыннан аларны алу ысуллары, шул исәптән электрон формада, аларны тапшыру тәртибе | Ай саен түләнә торган пособие билгеләнү өчен, гариза бирүче үзенең яшәү урыны адресын яки, үзе Россия Федерациясе Саклык банкы оешмасында (филиалында, структур бүлекчәсендә) ачкан счет реквизитларын күрсәтеп, гариза (бу Регламентка 1 нче кушымта) тапшыра, аңа түбәндәге документлар кушып бирелә:<br>а) мәгариф учреждениесенең баланың көндезге көндәлек уку формасында белем алуын раслаучы белешмәсе (ул 18 яшькә җиткәнгә кадәр һәр уку елында тапшырыла) – мәгариф учреждениесендә көндезге көндәлек уку формасында белем алучы өчен;<br>б) медицина-социаль экспертиза федераль учреждениесе тарафыннан бирелгән, балачактан инвалидлык бирелгәнне раслаучы белешмә – 18 яшькә җиткән бала өчен;<br>в) баланың әтисе хәрби хезмәткә чакырылганлыгын һәм аның чакырылыш буенча хәрби хезмәт узуын раслаучы, чакырылыш урынындагы хәрби комиссариаттан бирелгән белешмә;<br>г) хәрби хезмәткәрнең чакырылыш буенча хәрби хезмәт бурычларын үтәгәндә һәлак булганлыгын (үлгәнлеген, хәбәрсез килеш монда юк дип, билгеләнгән тәртиптә танылганлыгын, үлгән дип игълан ителгәнлеген) раслаучы документ күчермәсе, яисә хәрби табиблар комиссиясенең хәрби хезмәткәрнең | РФ Хөкүмәтенең № 481 карары белән расланган Кагыйдәләрнең 4 п. |

| | | |
|---|---|---|
| | (хезмәткәрнең) үлеменә китергән имгәнү яки чирнең хәрби җәрәхәт белән сәбәпле бәйләнеше турында йомгаклау нәтиҗәсе күчермәсе, яисә медицина-социаль экспертиза федераль учреждениесенең инвалидның, шулай ук хәрби хезмәт бурычларын (хезмәт итү бурычларын) үтәгәндә алган яралану, контузия алу, имгәнү яки чирләү нәтиҗәсендә зыян күргән затның үлеме сәбәбе турында, “хәрби җәрәхәт” формулировкасы белән белешмәсе күчермәсе.<br>Бу Регламентның 1.2 пунктындагы дүртенче абзацта күрсәтелгән балаларга ай саен түләнә торган пособие билгеләү турында гаризага бу пунктның “в” һәм “г” пунктчаларында күрсәтелгән документлар урынына, хәрби хезмәткәрнең (хезмәткәрнең) контракт буенча хәрби хезмәт бурычларын (хезмәт итү бурычларын) үтәгәндә һәлак булганлыгын (үлгәнлеген, хәбәрсез килеш монда юк дип, билгеләнгән тәртиптә танылганлыгын, үлгән дип игълан ителгәнлеген) раслаучы документ күчермәсе кушып бирелә.<br>д) ай саен түләнә торган пособие билгеләнүче баланың туу турындагы таныклыгы күчермәсе – баланың туу (уллыкка алыну) актын Татарстан Республикасыннан читтә теркәгән очракта;<br>е) үлү турындагы таныклык күчермәсе – үлү актын Татарстан Республикасыннан читтә теркәгән очракта.<br>Гариза бирүче документлар һәм белешмәләрне тиешле оешмалардан турыдан-туры ала, шул исәптән андый мөмкинлек булганда, электрон рәвештә.<br>Гариза бирүче, мөрәҗәгать иткәндә, шәхесен таныклаучы документ күрсәтә.<br>Дәүләт хезмәтен алучыларның законлы вәкилләре (закон белән күздә тотылган очракларда) яисә дәүләт хезмәтен алучылар | |

| | | |
|---|---|---|
| | вәкаләт биргән затлар, өстәмә рәвештә, аларның дәүләт хезмәтен алучының мәнфәгатьләрен яклауга вәкаләтләрен раслаучы документлар тапшыра.<br>Документларның күчермәләре Россия Федерациясе законнарына туры китереп расланмаган очракта, алар төп нөсхәләрен күрсәтеп тапшырыла һәм Идарә (бүлек) белгече тарафыннан раслана.<br>Дәүләт хезмәте алу өчен гариза бланкын гариза бирүче Идарәгә (бүлеккә) шәхсән мөрәҗәгать итеп алырга мөмкин. Бланкның электрон формасы Министрлыкның рәсми сайтына урнаштырылган.<br>Гариза бирүче гаризаны һәм аңа кушып бирелә торган документларны кәгазьдә шәхсән яисә почта аша тапшыра (җибәрә) ала.<br>Гариза почта аша җибәрелгәндә, аңа кушып бирелә торган документларның күчермәләре (шәхесне таныклаучы документ күчермәсеннән гайре) Россия Федерациясе законнарына туры китереп расланган булырга тиеш.<br>Гариза бирүче гаризаны һәм аңа кушып бирелә торган документларны квалификацияле көчәйтелгән электрон имза белән имзаланган электрон документлар рәвешендә гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәре аша, шул исәптән “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәре аша тапшыра (җибәрә) ала. | |
| 2.6. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен норматив-хокукый актлар нигезендә кирәкле, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагында булып, | Ведомствоара хезмәттәшлек каналлары аша түбәндәгеләрне раслаучы документлар алына:<br>балаларның тууын (уллыкка алынуын) дәүләт теркәве турында мәгълүматлар – баланың (балаларның) туу (уллыкка алыну) актын Татарстан Республикасы территориясендә теркәгән очракта (ЗАГС органнарыннан); | |

| | | |
|---|---|---|
| гариза бирүче тапшыруга хокуклы булган документларның тулы исемлеге, шулай ук гариза бирүчеләр тарафыннан аларны алу ысуллары, шул исәптән электрон формада, аларны тапшыру тәртибе; әлеге документлар алар карамагында булган дәүләт органы, җирле үзидарә органы яки оешма | үлүне дәүләт теркәве турында мәгълүматлар – үлү актын Татарстан Республикасы территориясендә теркәгән очракта (ЗАГС органнарыннан);<br>балага опекунлык яки химаячелек билгеләнү турында мәгълүматлар (опека һәм химая органнарыннан);<br>туендыручыны югалту очрагы буенча пенсия алу фактын раслаучы мәгълүматлар (Россия Федерациясе Пенсия фондыннан).<br>Гариза бирүче бу пунктта күрсәтелгән мәгълүматлар кергән документларны тапшырырга хокуклы, шул исәптән мөмкинлек булганда, электрон рәвештә.<br>Гариза бирүченең югарыда күрсәтеп үтелгән документларны тапшырмавы гариза бирүчегә хезмәт күрсәтүдән баш тартуга нигез булып тормый.<br>Гариза бирүче тапшыруга хокуклы булган документларны алу ысуллары һәм тапшыру тәртибе бу Регламентның 2.5 пункты белән билгеләнгән.<br>Дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагында булган югарыда санап кителгән документларны гариза бирүчедән таләп итү тыела. | |
| 2.7. Норматив-хокукый актларда күздә тотылган очракларда, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен аларның килештерүләре (дәүләт хезмәте күрсәтүче башкарма хакимият органы тарафыннан башкарыла) таләп ителә торган дәүләт хакимияте | Килештерү таләп ителми. | |

| | | |
|---|---|---|
| органнары һәм аларның структур бүлекчәләре исемлеге | | |
| 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тартуга нигезләрнең тулы исемлеге | 1. Бу Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар исемлегендәге документны тапшырмау.<br>2. Идарәгә (бүлеккә) гариза һәм документларны (документлар күчермәләрен) электрон имза белән № 63-ФЗ һәм № 210-ФЗ Федераль законнар таләпләренә туры китереп имзаланмаган (расланмаган) электрон документлар рәвешендә тапшыру.<br>3. Документларда билгеләнгән тәртиптә расланмаган бетерүләр, өстәп язулар, сызылган сүзләр һәм төзәтүләр булу.<br>4. Шәхсән мөрәҗәгать иткән очракта, документларның күчермәләре закон белән билгеләнгән тәртиптә расланмаган очракта, документларның төп нөсхәләрен күрсәтмәү.<br>5. Гариза бирүченең почта аша документларның Россия Федерациясе законнарына туры китереп расланмаган күчермәләрен җибәрүе. | |
| 2.9. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яки аннан баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып торуга нигезләр билгеләнмәгән.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартуга нигезләр булып тора:<br>бу Регламентның 1.3 пунктында күрсәтелмәгән затның документлар белән мөрәҗәгать итүе;<br>ялган (дөрес булмаган) мәгълүматлар кергән документлар тапшыру. | |
| 2.10. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен дәүләт пошлинасы яки башка түләү алу тәртибе, күләме һәм нигезләре | Дәүләт хезмәте түләүсез күрсәтелә. | |

| | | |
|---|---|---|
| 2.11. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булып торган хезмәтләргә түләү алу тәртибе, күләме һәм нигезләре, мондый түләү күләмен исәпләү методикасы турында мәгълүматны кертеп | Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми. | |
| 2.12. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында рәсми мөрәҗәгать тапшырганда һәм мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта көтүнең максималь срогы | Дәүләт хезмәте алу өчен мөрәҗәгать иткәндә, гариза бирүченең чиратта көтү вакыты 15 минуттан артык түгел.<br>Дәүләт хезмәте алучыларның аерым категорияләре өчен чират билгеләнмәгән. | РФ Президентының № 601 Указының 1 п. |
| 2.13. Гариза бирүченең дәүләт хезмәте күрсәтү турында рәсми мөрәҗәгатен (шул исәптән электрон рәвештәге) теркәү срогы | Гариза һәм документлар кергән көнне. | |
| 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган бүлмәләргә, гариза бирүчеләрнең көтү һәм аларны кабул итү урынына, шул исәптән, Россия Федерациясенең инвалидларны социаль яклау турындагы законнарына тәңгәл рәвештә, әлеге объектларның инвалидлар | Дәүләт хезмәте күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документлар рәсмиләштерү өчен кирәкле җиһазлар, мәгълүмат стендлары белән җиһазландырылган биналарда һәм бүлмәләрдә башкарыла.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү урыныннан инвалидларның тоткарлыксыз файдалана алуы, шул исәптән объектларга тоткарлыксыз керүе һәм алардан чыгуы, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтү урынына бару максатыннан, объект буйлап мөстәкыйль хәрәкәт итү мөмкинлеге тәэмин ителә.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм | |

| | | |
|---|---|---|
| файдалана алырлык булуын тәэмин итүгә, мондый хезмәтләрне күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиаль мәгълүмат урнаштыруга һәм рәсмиләштерүгә карата таләпләр | мультимедиаль мәгълүмат гариза бирүчеләр өчен уңайлы урыннарга, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып урнаштырыла. | |
| 2.15. Дәүләт хезмәтенең мөмкинлек һәм сыйфат күрсәткечләре, шул исәптән, дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә, гариза бирүченең вазыйфаи затлар белән аралашулары саны һәм аларның дәвамлылыгы, дәүләт хезмәтен дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәктә, дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урыннарында алу мөмкинлеге, дәүләт хезмәте күрсәтүнең барышы турында мәгълүматны алу мөмкинлеге, шул исәптән мәгълүмат-коммуникация | Дәүләт хезмәте күрсәтүнең мөмкинлек күрсәткечләре булып торалар:<br>Идарә (бүлек) биналарының җәмәгать транспорты йөри торган зонада урнашуы;<br>инвалидларга аларның хезмәт күрсәтүләрне башка затлар белән бертигез алуына комачаулаучы киртәләрне узуда ярдәм күрсәтү;<br>белгечләрнең, шулай ук гариза бирүчеләрдән документлар кабул итеп алына торган бүлмәләрнең кирәкле санда булуы;<br>Идарәнең (бүлекнең) мәгълүмат стендларында, “Интернет” челтәрендә, Министрлыкның рәсми сайтында дәүләт хезмәтен күрсәтү ысуллары, тәртибе һәм сроклары турында тулы мәгълүмат булу;<br>гаризаны электрон рәвештә бирү мөмкинлеге.<br>Гариза бирүче дәүләт хезмәте күрсәтүнең барышы турындагы мәгълүматны http://mtsz@tatarstan.ru сайтыннан, Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталыннан алырга мөмкин.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфат күрсәткечләре булып торалар:<br>документларны кабул итү һәм карап тикшерү сроклары үтәлү;<br>дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алу срогы үтәлү;<br>Идарә (бүлек) белгечләре тарафыннан Регламент бозылу | ТР МК № 880 карары белән расланган Тәртипнең 2.4 п.;<br>№ 601 РФ Президенты Указының 1 п. |

| | | |
|---|---|---|
| технологияләреннән файдаланып | очракларының (нигезле шикаятьләрнең) булу-булмавы;<br>гариза бирүченең Идарә (бүлек) белгечләре белән аралашуы саны:<br>дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны биргәндә, турыдан-туры – бердән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча);<br>дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны почта, шул исәптән электрон почта аша җибәргәндә, турыдан-туры аралашу таләп ителми.<br>Дәүләт хезмәте күрсәткәндә, гариза бирүченең Идарә (бүлек) белгече белән бер тапкыр аралашуының дәвамлылыгы 15 минуттан артмый.<br>Дәүләт хезмәте, дәүләт хезмәте күрсәтүгә гариза бирүне дә кертеп, күпфункцияле үзәк аша, дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урыннарында күрсәтелми. | |
| 2.16. Электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләре | Гариза һәм документларны (документлар күчермәләрен) гариза бирүче Идарәгә (бүлеккә) № 63-ФЗ Федераль закон һәм № 210-ФЗ Федераль закон таләпләре нигезендә, электрон имза белән имзаланган (расланган) электрон документлар рәвешендә җибәрелергә мөмкин. | № 63-ФЗ Федераль закон;<br>№ 210-ФЗ Федераль закон |

**3. Административ процедуралар (гамәлләр) составы, эзлеклелеге һәм аларны үтәү сроклары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән административ процедураларны (гамәлләрне) электрон формада үтәү үзенчәлекләре, шулай ук административ процедураларны күпфункцияле үзәкләрдә, дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урыннарында үтәү үзенчәлекләре**

3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүдә гамәлләр эзлеклелегенең тасвирламасы

3.1.1. Ай саен түләнә торган пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

гариза бирүчегә консультация бирү, гариза бирүчегә ярдәм күрсәтү, шул исәптән гариза язу өлешендә дә;

гаризаны кушып бирелүче документлар пакеты белән бергә кабул итү һәм теркәү яисә документларны кабул итүдән баш тарту;

мәгълүматлар алу, дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр төзү һәм җибәрү;

ай саен түләнә торган пособие билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) карар әзерләү һәм кабул итү;

гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү;

техник хатаны (ялгыш язу, басмада ялгышлык, грамматик яки арифметик хатаны) төзәтү.

3.1.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча гамәлләр эзлеклелегенең блок-схемасы бу Регламентка 2 нче кушымтада бирелә.

3.2. Гариза бирүчегә консультация бирү, гариза бирүчегә ярдәм күрсәтү, шул исәптән гариза язу өлешендә дә

Гариза бирүче, дәүләт хезмәте алу тәртибе турында консультацияләр алу өчен, Идарәгә (бүлеккә) шәхсән үзе, телефоннан, электрон почта аша һәм (яки) хат белән мөрәҗәгать итә.

Идарә (бүлек) белгече, гариза бирүченең мөрәҗәгать итү ысулына бәйле рәвештә, шәхсән үзе, телефоннан, электрон почта аша һәм (яки) хат белән гариза бирүчегә консультация үткәрә, шул исәптән дәүләт хезмәте алу өчен кирәкле документларның составы, формасы һәм эчтәлеге ягыннан, гариза бланкын бирә, һәм зарурлык булганда, гариза бирүчегә ярдәм күрсәтә, шул исәптән гариза язу өлешендә дә.

Бу пункт билгели торган процедура гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне үтәлә.

Процедура нәтиҗәсе: консультация, тапшырылган документларның составы, формасы һәм эчтәлеге ягыннан искәртмәләр, гариза бирүчегә ярдәм күрсәтү, шул исәптән гариза язу өлешендә дә.

3.3. Гаризаны кушып бирелүче документлар пакеты белән бергә кабул итү һәм теркәү яисә документларны кабул итүдән баш тарту.

3.3.1. Гариза бирүче Идарәгә (бүлеккә) ай саен түләнә торган пособие билгеләү турында гариза һәм аңа кушып, бу Регламентның 2.5 пункты нигезендә, документлар бирә.

Гариза һәм документларның Россия Федерациясе законнарына туры китереп расланган күчермәләре почта аша, җибәрү фактын һәм көнен расларга мөмкинлек бирүче ысул белән җибәрелергә мөмкин.

Электрон документлар рәвешендәге, № 63-ФЗ Федераль закон һәм № 210-ФЗ Федераль закон таләпләренә туры китереп, гариза бирүченең электрон имзасы белән имзаланган (расланган) гариза һәм документлар күчермәләре гариза бирүче тарафыннан Идарә (бүлеккә) электрон чараларны кулланып һәм (яки) "Интернет" челтәрен дә кертеп, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән файдаланып тапшырылырга мөмкин.

Идарә (бүлек) белгече түбәндәгеләрне башкара:

законлы вәкил сыйфатында эш итүче гариза бирүченең яисә дәүләт хезмәте алучы тарафыннан вәкаләт бирелгән затның вәкаләтләрен тикшерә;

документларны кабул итүдән баш тартуга бу Регламентның 2.8 пункты белән күздә тотылган нигезләр булу-булмавын тикшерә.

Документларны кабул итүдән баш тартуга нигезләр булмаган очракта, Идарә (бүлек) белгече түбәндәгеләрне башкара:

гаризаны кабул итә һәм гражданнарның мөрәҗәгатьләрен теркәү журналында (3 нче кушымта) терки;

гариза бирүчегә гаризасын һәм документларын кабул итү датасы, бирелгән керү номеры турында билге белән расписка тапшыра (гариза бирүче шәхсән мөрәҗәгать иткәндә), гариза почта аша һәм (яки) гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән, шул исәптән "Интернет" челтәреннән файдаланып җибәрелгәндә – гаризаны теркәү көне һәм бирелгән керү номеры турында хәбәрнамә җибәрә.

Документларны кабул итүдән баш тартуга нигезләр булган очракта, Идарә (бүлек) белгече мөрәҗәгать итүчегә (шәхсән мөрәҗәгать иткәндә) документларны кабул итүдән һәм гаризаны теркәүдән баш тартуга нигезләр булу турында телдән хәбәр итә һәм, документларны һәм гаризаны кабул итүдән баш тартуның ачыкланган нигезләренең эчтәлеген аңлатып, документларны аңа кире кайтара. Гариза бирүченең таләбе буенча, баш тарту язмача рәсмиләштерелә. Гариза почта аша һәм (яки) гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәре аша, "Интернет" челтәрен дә кертеп, алынганда, Идарә (бүлек) белгече, документларны кабул итүдән һәм гаризаны теркәүдән баш тартуның сәбәбен язмача аңлатып, гариза һәм документларны кире кайтара.

Бу пункт билгели торган процедуралар үтәлә:

шәхсән кабул иткәндә яисә гариза һәм документлар почта аша кергәндә – гариза һәм документлар кергән көнне;

гариза гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәре аша, "Интернет" челтәрен дә кертеп, кергәндә – гариза һәм документлар Идарәгә (бүлеккә) кергән көнне яисә, гариза һәм документлар Идарәнең (бүлекнең) эш вакыты тәмамлангач кергән очракта, икенче көнне. Гариза һәм документлар электрон документлар рәвешендә ял яки эшләми торган бәйрәм көннәрендә кергән очракта – Идарәнең (бүлекнең) ял яки эшләми торган бәйрәм көннән соң килүче беренче эш көнендә.

Процедуралар нәтиҗәсе: кабул ителгән документлар, гражданнарның мөрәҗәгатьләрен теркәү журналында теркәү язуы булдыру, расписка яки гариза бирүчегә кире кайтарылган документлар, документларны кабул итүдән баш тарту турында гариза бирүчегә телдән (язмача) хәбәр итү.

3.4. Мәгълүматлар алу, дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр төзү һәм җибәрү

3.4.1. Идарә (бүлек) белгече электрон рәвештә ала:

2013 елның 23 октябреннән соң туган балаларның тууын дәүләт теркәве турында мәгълүматлар – туу акты Татарстан Республикасы территориясендә теркәлгән очракта (ЗАГС органнарыннан);

үлүне дәүләт теркәве турында мәгълүматлар – үлү акты Татарстан Республикасы территориясендә теркәлгән очракта (ЗАГС органнарыннан);

туендыручыны югалту очрагы буенча пенсия алу фактын раслаучы мәгълүматлар (Россия Федерациясе Пенсия фондыннан).

Идарәдә (бүлектә) ай саен түләнә торган пособие билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) карар кабул итү өчен кирәкле мәгълүматлар булмаганда, Идарә (бүлек) белгече, ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы ярдәмендә, түбәндәге мәгълүматларны бирүне сорап, электрон рәвештә рәсми мөрәҗәгатьләр җибәрә:

2013 елның 23 октябренә кадәр туган балаларның тууын дәүләт теркәве турында – туу акты Татарстан Республикасы территориясендә теркәлгән очракта (ЗАГС органнарына);

балага опека (химая) билгеләнү турында мәгълүматлар (опека һәм химая органнарына).

Бу пункт билгели торган процедуралар гариза һәм документлар кабул ителгән һәм теркәлгән көнне үтәлә.

Процедуралар нәтиҗәсе: электрон рәвештә алынган мәгълүматлар, мәгълүматлар бирү турында рәсми мөрәҗәгатьләр.

3.5. Ай саен түләнә торган пособие билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) карар әзерләү һәм кабул итү

3.5.1. Бу Регламентның 3.4.1 пунктчасында күрсәтелгән алынган мәгълүматлар һәм гариза бирүче тапшырган документлар нигезендә, Идарә (бүлек) белгече түбәндәгеләрне башкара:

дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен бу Регламентның 2.9 пунктында күздә тотылган нигезләр булу-булмавын тикшерә;

бу Регламентка 4 нче кушымта нигезендәге форма буенча ай саен түләнә торган пособие билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) карар проектын рәсмиләштерә;

ай саен түләнә торган пособие билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) карар проектын Идарә (бүлек) җитәкчесенә имза куюга җибәрә.

Бу пункт билгели торган процедуралар гариза теркәлгән көннән башлап ике эш көне эчендә үтәлә. Ведомствоара хезмәттәшлек каналлары буенча документлар сорап алу зарурлыгы булганда – рәсми мөрәҗәгатьләргә җаваплар кергән көннән башлап ике эш көне эчендә, ләкин гариза теркәлгән көннән башлап

җиде эш көненнән дә соңга калмыйча.

Процедуралар нәтиҗәсе: ай саен түләнә торган пособие билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) Идарә (бүлек) җитәкчесенә имза куюга җибәрелгән карар проекты.

3.5.2. Документларны карап тикшергәннән соң, Идарә (бүлек) җитәкчесе ай саен түләнә торган пособие билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) электрон рәвештәге карарны имзалый һәм Идарә (бүлек) белгеченә җибәрә.

Бу пункт билгели торган процедура ай саен түләнә торган пособие билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) карар проекты имза куюга җибәрелгән көннән алып бер эш көне эчендә үтәлә.

Процедура нәтиҗәсе: ай саен түләнә торган пособие билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) Идарә (бүлек) җитәкчесе тарафыннан имзаланган карар.

3.6. Гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү

